ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 527-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Р.А. Ратникова, А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 527-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 15 феврале
№ 2340-VI ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Р.А. Ратникова,
А.Г. Хәбибуллин тарафыннан
кертелә

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

**Татарстан Республикасы Законы**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяның 1 өлешендә:
а) 9 пунктка «оештыру» сүзеннән соң «, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә тиешле муниципаль район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек хакында җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү» сүзләрен өстәргә;

б) 28 пунктта «гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү, гомуми файдаланудагы су объектларыннан һәм аларның яр буе полосаларыннан гражданнарның ирекле файдалана алуын тәэмин итүне дә кертеп» сүзләрен «гомуми файдаланудагы су объектларыннан һәм аларның яр буе полосаларыннан гражданнарның ирекле файдалана алуын тәэмин итүне дә кертеп, гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен, шулай ук рекреация максатлары өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен билгеләү» сүзләренә алмаштырырга;

2) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) 11 пунктта «оештыру» сүзеннән соң «, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә тиешле шәһәр округы территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек хакында җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү» сүзләрен өстәргә;

б) 36 пунктта «гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү һәм мондый су объектларыннан файдаланудагы чикләүләр турында халыкка мәгълүмат бирү, гомуми файдаланудагы су объектларыннан һәм аларның яр буе полосаларыннан гражданнарның ирекле файдалана алуын тәэмин итүне дә кертеп» сүзләрен «гомуми файдаланудагы су объектларыннан һәм аларның яр буе полосаларыннан гражданнарның ирекле файдалана алуын тәэмин итүне дә кертеп, гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен, шулай ук рекреация максатлары өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен билгеләү һәм мондый су объектларыннан файдаланудагы чикләүләр турында халыкка мәгълүмат бирү» сүзләренә алмаштырырга;

3) $49^1$ статьяда:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирле үзидарә органнары әлеге статьяның 2 өлешендәге 2 – 5 пукнтларында каралган халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыра башлауның күздә тотылган датасына кадәр 45 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруны килештерү турында мөрәҗәгать җибәрә.

Әлеге статьяның 2 өлешендәге 1 пунктында каралган халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруны килештерү турында мөрәҗәгать җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыра башлауның күздә тотылган датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.»;

б) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Әлеге статьяның 3 өлешендәге беренче абзацында каралган очракта халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруны килештерү турында җирле үзидарә органының мөрәҗәгатен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан карау нәтиҗәләре халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыра башлауның күздә тотылган датасына кадәр 15 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша әлеге мөрәҗәгатьне җибәргән җирле үзидарә органына җиткерелә.

Әлеге статьяның 3 өлешендәге икенче абзацында каралган очракта халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруны килештерү турында җирле үзидарә органының мөрәҗәгатен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан карау нәтиҗәләре халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыра башлауның күздә тотылган датасына кадәр өч көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша әлеге мөрәҗәгатьне җибәргән җирле үзидарә органына җиткерелә.»;

4) $49^2$ статьяның 1 өлешендә «1. Җирле үзидарә органының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турындагы килешү» сүзләреннән соң «(төп нөсхәсе)» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасыннан һәм 2 пунктының «а» пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасы һәм 2 пунктының «а» пунктчасы 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Закон проекты «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын федераль законнарга кертелгән үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән.

«Россия Федерациясенең су кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 657-ФЗ номерлы Федераль закон белән муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә рекреация максатларында су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен билгеләү кертелгән.

Моннан тыш, 2024 елның 1 сентябреннән «Экологик экспертиза турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Җирләрне яисә җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү турында» Федераль законның 2 статьясындагы 4 өлешенең 4 пунктының үз көчен югалтуын тану хакында» муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының әйләнә-тирә мохит өлкәсендәге мәсьәләләре төгәлләштерелгән Федераль закон гамәлгә керәчәк.

Аерым алганда, җирле үзидарә органнары тарафыннан әйләнә-тирә мохитне саклау буенча үткәрелә торган чараларга, шулай ук, планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында халык арасында фикер алышуны үткәрү дә кертелә. Җәмәгать фикер алышулары әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә оештырыла.

Федераль законнардагы бәян ителгән яңалыкларны исәпкә алып, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына шундый ук үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

Шулай ук, хокук куллану тәҗрибәсен истә тотып, закон проектында җирле үзидарә органнарының чит дәүләтләрнең дәүләти-территориаль, административ-территориаль һәм муниципаль берәмлекләре вәкилләре белән очрашулар, консультацияләр һәм башка чаралар рәвешендәге халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештерү срокларын кыскарту карала.

---

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалтуы танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы закон актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы закон актларының үз көчен югалтуын тану, туктатып тору, үзгәртү яисә кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.